# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Яшьләр һәм Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

"Яшьләр һәм Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында" 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 маендагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 11; 2005, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

"яшьләр арасында этникара һәм конфессияара толерантлык дәрәҗәсен күтәрү, этник һәм (яисә) конфессиональ дошманлык нигезендә яшьләрнең экстремистлык берләшмәләрен формалаштыруга юл куймау;";

б) сигезенче абзацны тугызынчы абзац дип санарга;

2) 5 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче абзац өстәргә:

"барлык дәрәҗәләрдәге мәгариф системасына үсеп килүче буынны граждан татулыгы һәм толерантлык рухында тәрбияләүгә юнәлдерелгән уку-укыту материалларын һәм технологияләрен кертү;";

б) бишенче һәм алтынчы абзацларны алтынчы һәм җиденче абзацлар дип санарга;

в) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

"яшьләрнең һөнәри үсешенә ярдәм итүче, яшьләрдә уңай хезмәт мотивацияләре, югары эшлекле активлык, профессиональләштерүнең төп принципларына, хезмәт базарында нәтиҗәле эшләү күнекмәләренә уңышлы ия булуга ярдәм итүче чараларны гамәлгә ашыру;";

г) җиденче – унынчы абзацларны тугызынчы – уникенче абзацлар дип санарга;

3) 6 статьяның бишенче абзацында "күренешләрне" сүзеннән соң ", шул исәптән милли һәм конфессиональ җирлектә дискриминация, көч куллану, расизм һәм экстремизм чагылышларын" сүзләрен өстәргә;

4) 7 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

"хезмәт базары ихтыяҗлары нигезендә һөнәри белем бирү буенча хезмәт күрсәтүләргә яшьләрнең ихтыяҗын формалаштыруга ярдәм итүче чаралар күрү; ";

б) өченче – бишенче абзацларны дүртенче – алтынчы абзацлар дип санарга;

5) 8 статьяның икенче абзацында "яшьләрдә татар халкының һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыклар вәкилләренең традицияләренә, гореф-гадәтләренә һәм мәдәниятенә кызыксыну һәм ихтирам формалаштыру" сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан, Кремль
2009 елның 22 июне
№ 20-ТРЗ